КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 6 июль г.Казань № 556

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2020 елларда Татарстан Республикасы мәгариф системасында стажировка һәм база мәйданчыклары эшен оештыру турында» 2016 ел, 9 июль, 468 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2020 елларда Татарстан Республикасы мәгариф системасында стажировка һәм база мәйданчыклары эшен оештыру турында» 2016 ел, 9 июль, 468 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 сентябрь, 741 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы турында» 2015 ел, 23 май, 497 нче карары белән расланган 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасын» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1642 нче карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын» сүзләренә алыштырырга;

1 нче һәм 2 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1642 нче карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту, яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү

концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чараларын тормышка ашыру өчен «Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирә торган дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә стажировка мәйданчыгы статусын бирергә.

2. «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1642 нче карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чаралары буенча стажировка мәйданчыгы, аларда катнашучы мәктәпләр һәм «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1642 нче карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чаралары буенча гомуми белем бирү системасында стажировка мәйданчыгы һәм база мәйданчыклары турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) расларга.

3 нче пунктта «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту» дигән 2.2 чарасы буенча стажировка мәйданчыгы, аларда катнашучы мәктәпләр һәм 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү» дигән 2.4 чарасы буенча гомуми белем бирү системасында стажировка мәйданчыгы һәм база мәйданчыклары турындагы нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1642 нче карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чаралары буенча стажировка мәйданчыгы, аларда катнашучы мәктәпләр һәм «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын

раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1642 нче карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чаралары буенча гомуми белем бирү системасында стажировка мәйданчыгы һәм база мәйданчыклары турында нигезләмә»;

1.1 нче пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1642 нче карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының (алга таба – «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы) төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чаралары буенча стажировка мәйданчыгын, аларда катнашучы мәктәпләрне оештыру шартларын һәм аларның эшләү тәртибен;

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чаралары буенча гомуми белем бирү системасында стажировка мәйданчыгын һәм база мәйданчыкларын оештыру шартларын һәм аларның эшләү тәртибен.»;

1.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чаралары буенча стажировка мәйданчыгы, аларда катнашучы мәктәпләр һәм «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чаралары буенча гомуми белем бирү системасында стажировка мәйданчыгы һәм база мәйданчыклары үз эшчәнлекләрендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм бу Нигезләмәгә таянып эш итә.»;

1.3 нче пунктта:

беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Стажировка мәйданчыгы – «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын

яхшырту чаралары буенча һәм «Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирә торган дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең (алга таба – Институт) өстәмә һөнәри белем бирү буенча мәгариф программалары кысаларында «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чаралары буенча стажировка рәвешендә гомуми белем бирү системасы хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү өчен мәгариф оешмасы базасында оештырылган структура.

База мәйданчыгы – базаларында «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чаралары кысаларында стажировка (тулысынча яки өлешчә) рәвешендә мәгариф системасының педагог һәм җитәкче хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү буенча өстәмә һөнәри белем бирү программалары тормышка ашырыла торган гомуми белем бирү оешмасы, өстәмә һөнәри белем бирү оешмасы, һөнәри белем бирү оешмасы, югары белем бирә торган мәгариф оешмасы, коммерциячел булмаган оешма.»;

өченче абзацта «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту» дигән 2.2 нче чарасы буенча» сүзләрен «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чаралары буенча» сүзләренә алыштырырга;

1.4 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чаралары буенча һәм «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чаралары буенча стажировка мәйданчыгы статусы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән түбәндәгеләргә бирелә:»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чаралары буенча база мәйданчыгы статусы мәгариф оешмасына база мәйданчыкларын конкурс нигезендә сайлап алу буенча бирелә. База мәйданчыкларын конкурс нигезендә сайлап алу Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә башкарыла, һәм ул түбәндәгеләрне раслый: нигезендә сайлап алу турында игълан, конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен заявка формасы, конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү хакында нигезләмә, конкурс материалларын бәяләү методикасы, эксперт бәяләмәсе формасы, республика конкурс комиссиясе составы, эксперт комиссиясе составы.»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чараларында катнашучы мәктәп тикшерү нәтиҗәләре нигезендә ел саен стажировка мәйданчыгы белән сайлап алына, Катнашучы мәктәпләр исемлегенә керә һәм Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.»;

1.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. «Мәгариф оешмасына «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чаралары буенча стажировка мәйданчыгы һәм аларда катнашучы мәктәп статусын һәм «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чаралары буенча стажировка мәйданчыгы һәм база мәйданчыгы статусын бирү мәгариф оешмасының оештыру-хокукый формасын, тибын һәм төрен үзгәртүгә китерми.»;

1.6 нчы пунктның беренче һәм икенче абзацларында «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының» сүзләрен «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының» сүзләренә алыштырырга;

2.2 нче пунктта «2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының» сүзләрен «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының» сүзләренә алыштырырга;

2.3 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда

эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чаралары буенча стажировка мәйданчыгы эшчәнлегенең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чаралары буенча стажировка мәйданчыгы эшчәнлегенең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:»;

3.1 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чаралары буенча стажировка мәйданчыгы функцияләре булып түбәндәгеләр тора:»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чаралары буенча стажировка мәйданчыгы функцияләре булып түбәндәгеләр тора:»;

4.1 нче пунктта 2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алыштырырга;

4.2 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чаралары буенча стажировка һәм база мәйданчыклары статусы бирелгән мәгариф оешмалары эшчәнлегенә бәйле чыгымнарны тәэмин итү өчен күздә тотылган федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы акчасы түбәндәгеләргә бүлеп бирелә:»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чараларын тормышка ашыру нәтиҗәлелелегенә мониторинг үткәрүгә.»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту

нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чаралары буенча стажировка мәйданчыгы һәм аларда катнашучы мәктәпләр статусы бирелгән мәгариф оешмалары эшчәнлегенә бәйле чыгымнарны тәэмин итү өчен күздә тотылган федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы акчасы «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чараларын тормышка ашыру нәтиҗәлелегенә мониторинг үткәрүгә җибәрелә.»;

5.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чаралары буенча стажировка һәм база мәйданчыклары эшчәнлеге «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү буенча төбәк программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү чараларын тормышка ашыру вакыты тәмамланган очракта туктатыла.

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чаралары буенча стажировка мәйданчыгы һәм аларда катнашучы мәктәпләр эшчәнлеге «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының төбәк проектларын тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен тарату юлы белән укыту нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләрдә һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләрдә белем бирүнең сыйфатын яхшырту чараларын тормышка ашыру вакыты тәмамланган очракта туктатыла.»;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин